«40. Төзелеш проектын гамәлгә ашыру графигы, ул аны тормышка ашыру этаплары һәм вакытын, шул исәптән Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт алу срогы турында мәгълүматны үз эченә ала»;

5 бүлектә:

5.27 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

5.43 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

5.66 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

5.69-5.72 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.69. Әлеге административ гамәлне үтәү өчен җаваплы булган вазыйфаи затлары булып Бүлекнең һәм Инспекциянең документлар белән тәэмин итү һәм контроль бүлегенең җаваплы вазыйфаи затлары тора.

5.70. Хисаплылык түбәндәге рәвештә дә җибәрелә ала:

- Инспекциягә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә (яисә вәкаләтле вәкил аша) кәгазь документ рәвешендә;

- теркәлгәннәр исемлеге һәм кулга тапшыру турында белдерү белән почта адресы буенча җибәргәндә кәгазь документ рәвешендә;

- төзүче оешманың шәхси кабинеты аша торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасыннан җибәргәндә электрон документ рәвешендә.

Кәгазь документ рәвешендә бирелә торган хисаплылык (аңа кушымталарны да кертеп) тегелгән һәм номерланган булырга тиеш.

Инспекциягә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә хисаплылык тапшырылган очракта, төзүче оешманың Инспекциягә хисаплылык тапшыруга вәкаләтен таныклый торган ышанычнамә теркәлә. Хисаплылык шәхсән мөрәҗәгать итү барышында алынганда Инспекциянең вазыйфаи заты тарафыннан ике нөсхәдә кабул итү акты төзелә, анда аның тарафыннан алынган документларның исемлеге, аның тарафыннан хисаплылыкны алу датасы, төзүче оешманың вәкиле турында һәм хисаплылык составында аның хисаплылыкны тапшыруга вәкаләтен таныклый торган документның булуы турында белешмәләр, шулай ук хисаплылыкны кабул иткән һәм кабул итү актын төзегән Инспекция хезмәткәренең вазыйфа аталышы, фамилиясе, исеме һәм ата исеме (соңгысы – булган очракта) күрсәтелгән була. Кабул итү акты Инспекциягә шәхсән мөрәҗәгать иткән көнне кулга тапшырыла. Бер нөсхәсе төзүче оешма вәкиленә тапшырыла, икенче нөсхәсе бүлеккә тапшырыла.

Хисаплылыкны төзүче оешманың торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасындагы шәхси кабинеты аша электрон документ рәвешендә тапшырган очракта, хисаплылык һәм аның кушымталары төзүче оешманың бер кулдагы башкарма органы вазыйфаларын гамәлгә ашыручы затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

5.71. Хисаплылык хисап кварталы тәмамланганнан соң 30 календарь көненнән соңга калмыйча һәм IV квартал тәмамланганнан соң 90 көннән соңга калмыйча тапшырыла. Шул ук вакытта төзүче оешма тарафыннан хисаплылыкны тапшыру датасы булып почта аша җибәрелү датасы, хисаплылыкны кабул итү актында күрсәтелгән дата яисә төзүче оешманың торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасындагы шәхси кабинетында хисаплылыкны урнаштыру датасы тора.

